**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

0.09.2021 г.Казань № 354

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге турында нигезләмәне раслау турында

2004 елның 27 июленнән «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февраленнән «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге турында» 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 мартыннан «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә бәйгеләр үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» 397 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартыннан УП-127 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау турында» һәм 2015 елның 11 декабреннән УП-1192 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә һәм дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тестлар оештыру мәсьәләләре» указлары нигезендә

**боерам:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге турында теркәлә торган Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Министрлыкның 2019 елның 19 мартыннан 80 нче номерлы «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге турында Нигезләмәне раслау турында» һәм 2021 елның 9 февраленнән 43 номерлы «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» боерыкларын гамәлдән чыккан дип санарга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының
__30.09.2021_________ нан
__354___номерлы боерыгы
белән раслана

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына кертүгә) бәйге турында
**НИГЕЗЛӘМӘ**

I ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә. Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге (алга таба – бәйге) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә тигез керү хокукын, шулай ук дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) бәйге нигезендә вазыйфаи үсеш хокукын тәэмин итә.

1.1. Министрлыкта бәйге 2004 елның 27 июленнән «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 22 маддәсе, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февраленнән «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге турында» 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 мартыннан «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә бәйгеләр уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 397 нче номерлы карары, 2003 елның 16 гыйнварыннан «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 3-ЗРТ), Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартыннан «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендә кадрлар

резервы турында Нигезләмәне раслау хакында» УП-127 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11 декабреннән «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре» УП-1192 номерлы Указы нигезендә үткәрелә.

1.2. Министрлыкта бәйге Татарстан Республикасы спорт министры карары буенча (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) Федераль закон һәм 3-ЗРТ нигезендә аны биләү бәйге нигезендә башкарыла торган гражданлык хезмәтендә вакантлы вазыйфа булганда игълан ителә.

1.3. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә бәйге Министрлыкның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен һәм булган кадрлар резервын Министрлыкның белгечләргә ихтыяҗын бәяләү нәтиҗәләре буенча кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре секторы тарафыннан оештырыла.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә бәйге Министрлыкның бәйге комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Бәйге түбәндәге очракларда үткәрелми:

а) «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары вәкаләтләрен билгеле вакытка биләүгә билгеләгәндә;

б) вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

в) гражданлык хезмәткәрен Федераль законның 28 маддәсендәге 2 өлешендә, 31 маддәсендәге 1 өлешендә һәм $60^1$ маддәсендәге 9 өлешендә каралган очракларда гражданлык хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

г) гражданлык хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәре (гражданы) вазыйфасына билгеләп куйганда.

1.6. Бәйге түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

а) вазыйфаи бурычларны үтәү Министрлык боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр куллануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләнгәндә;

б) министр карары буенча гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә караган гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә.

## II БӘЙГЕДӘ КАТНАШУЧЫЛАР

2.1. Бәйгедә катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары нигезендә билгеләнгән гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданнары ия.

Гражданлык хезмәткәре бәйге үткәрү чорында, нинди вазыйфа биләвенә карамастан, гомуми нигезләрдә бәйгедә катнашырга хокуклы.

2.2. Бәйгедә катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) фотография белән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкета;

в) паспорт яисә аны алмаштыручы документ күчермәсе (тиешле документ бәйгегә килгәч шәхсән тапшырыла);

г) кирәкле һөнәри белем, квалификация һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең нотариаль рәвештә яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте раслаган күчермәсе (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш), яисә электрон хезмәт кенәгәсе яки гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

белем һәм квалификация турында документларның нотариаль рәвештә яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган күчермәләре, шулай ук гражданның теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрү яки бирүне раслый торган документлар, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документлар күчермәләре;

д) гражданның гражданык хезмәтенә керүгә яки аны узуга комачаулый торган авыруы булмавы турында документ;

е) Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

2.3. Гражданлык хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органында бәйгедә

катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре министр исеменә гариза бирә.

2.4. Башка дәүләт органында үткәрелә торган бәйгедә катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре бу дәүләт органына эшкә алучының вәкиле исеменә гариза һәм фотография белән аның тарафыннан имзаланган һәм гражданлык хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте раслаган Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча анкета тапшыра.

2.5. Әлеге Нигезләмәнең 2.2-2.4 пунктларында күрсәтелгән документлар «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Министрлыкның һәм «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итү бердәм мәгълүмати системасы» дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмати системасының (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) рәсми сайтларында аларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 21 календарь көн эчендә Министрлыкка граждан (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып электрон рәвештә җибәрелә.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки җитди сәбәпсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданның (гражданлык хезмәткәренең) аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки җитди сәбәп аркасында рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

2.6. Әгәр граждан (гражданлык хезмәткәре) биләргә (кадрлар резервына кертергә) дәгъва итә торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган серләр белән эш итүгә бәйле булса, граждан (гражданлык хезмәткәре) ризалыгы белән, аны шундый белешмәләргә кертүне рәсмиләштерү процедурасы уздырыла.

Граждан тарафыннан Министрлыкка бирелгән белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә бирелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә дучар ителә.

Гражданлык хезмәткәре тапшырган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә караган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә үткәрелгән бәйгедә катнашкан очракта гына гамәлгә ашырыла.

2.7. Граждан (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәүгә, шулай ук гражданлык хезмәтенә керү һәм аны узу өчен дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә бәйгедә катнашуга кертелми.

## III БӘЙГЕ КОМИССИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Бәйге ике этапта үткәрелә. Беренче этапта Министрлык һәм «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итү бердәм мәгълүмати системасы» дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмати системасының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларында бәйгедә катнашу өчен документлар кабул ителү турында игълан, шулай ук бәйге турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: гражданлык хезмәтендәге вакантлы вазыйфа атамасы, әлеге вазыйфаны биләү өчен куелган квалификацион таләпләр, әлеге Нигезләмәнең 6 пункты нигезендә тәкъдим ителергә тиешле документлар кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документлар кабул итү тәмамлану вакыты, бәйгене үткәрергә ниятләгән көн, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, вазыйфаи регламент, бәйге кысаларыннан тыш үзеңнең һөнәри дәрәҗәне мөстәкыйль рәвештә билгеләү өчен беренчел квалификацион текстка сылтама, башка мәгълүмати материаллар. Бәйгедә катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан һәм бәйге турында мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта басылып чыгарга мөмкин.

3.2. Бәйгенең икенче этабын үткәрүнең көне, урыны һәм вакыты турында карар министр тарафыннан гражданлык хезмәтендәге вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучылар тарафыннан тәкъдим ителгән мәгълүматларның дөреслеген тикшергәннән соң, шулай ук кирәк очракта дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка төрле серләрне тәшкил иткән мәгълүматларны ачу мөмкинлеген рәсмиләштергәннән соң кабул ителә. Бәйгенең икенче этабы бәйгедә катнашу өчен

документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча үткәрелә, ә дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка төрле серләрне тәшкил иткән мәгълүматларны ачу мөмкинлеген рәсмиләштергән очракта, бәйгенең икенче этабын үткәрү вакыты эшкә алучы вәкиле тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның гражданлык хезмәтенә алынуына каршы килә торган шартлар барлыгы ачыкланган очракта, аңа министр тарафыннан бәйгедә катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында язма рәвештә хәбәр җиткерелә. Әгәр граждан бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә юллаган булса, бәйгедә катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында белдерү кәгазе аңа Федераль мәгълүмати системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

3.3. Бәйгедә катнашуга уздырылмаган дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы әлеге карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

3.4. Министрлык бәйгенең икенче этабы башланганчы 15 календарь көннән дә соңга калмыйча «Интернет» челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итү бердәм мәгълүмати системасы» дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмати системасының рәсми сайтында бәйгенең үткәрүнең көне, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, бәйгедә катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеген урнаштыра, һәм кандидатларга язма формада, ә бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тәкъдим иткән кандидатларга – Федераль мәгълүмати системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тиешле хәбәр юллый,

3.5. Бәйгене үткәрү нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә куелган квалификация таләпләренә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланмаган очракта, министр яңа бәйге үткәрү турында карар кабул итәргә мөмкин.

3.6. Бәйгеләрне үткәрү өчен Министрлык боерыгы нигезендә даими нигездә эшли торган бәйге комиссиясе төзелә. Бәйге комиссиясе составы, аның эш вакыты

һәм тәртибе Министрлык боерыгы белән билгеләнә.

3.7. Бәйге комиссиясе составына министр һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән (шул исәптән кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча сектордан һәм дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге үткәрелә торган бүлекчәдән) гражданлык хезмәткәрләре, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкиләре, шулай ук бәйге комиссиясе составына кертелә торган бәйсез экспертлар – фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар вәкилләре, тиешле өлкәләрдә һәм гражданлык хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә кадрлар технологияләре һәм гражданлык хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булып торучы, министр соравы буенча законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырылучы белгечләр керә.

Бәйсез экспертның бәйге комиссиясендә булу вакыты гомумән алганда өч елдан артмаска тиеш. Әлеге вакытны исәпләү бәйсез экспертның бәйге комиссиясе составына беренче кертелгәннән башлана. Әлеге бәйсез экспертны бәйге комиссиясе составына кабат кертү бәйге комиссиясендә булу вакыты тәмамланып өч ел узганнан соң гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны бәйге комиссиясе әгъзаларының гомуми санынnan кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

Дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне куллануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

Бәйге комиссиясе составы бәйге комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыклары барлыкка килү мөмкинлеге төшереп калдырылырлык итеп формалаштырыла.

3.8. Бәйге комиссиясе комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатибе һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Комиссия рәисе бәйге комиссиясе эшчәнлеге белән идарә итә. Комиссия рәисе булмаган очракта аның хокуклары һәм вәкаләтләрен бәйге комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Бәйге комиссиясе сәркатибе комиссия эшен (гаризалар кабул итү, эшләр ачу, бәйге комиссиясе карарларын теркәү һ.б.) тәэмин итә.

3.9. Бәйге гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын билүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

Бәйге үткәрү барышында бәйге комиссиясе кандидатларны белем алу, гражданлык яки башка дәүләт хезмәтен узу, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы документлар нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән ысулларын кулланып, бәйге процедуралары нигезендә бәяли, шул исәптән шәхси әңгәмә, анкеталау, төркемле дискуссияләр үткәрү, реферат яки тестлар язу, кандидатлар дәгъва кыла торган дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын башкару белән бәйле сораулар буенча тестларны да кертеп.

Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәялəгәндә бәйге комиссиясе граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

3.10. Бәйге комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат булса (кадрлар резервына кертү) һәм аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Бәйге комиссиясе утырышын аның бары тик гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

Бәйге нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавыш тигез булганда бәйге комиссиясе утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

3.11. Бәйге комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләү яисә бу вазыйфага билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Бәйге комиссиясе шулай ук дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә үткәрелгән бәйгедә җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси

сыйфатларына югары бәя бирелгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итәргә хокуклы.

3.12. Бәйге комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган карар белән рәсмиләштерелә.

3.13. Бәйге нәтиҗәләре буенча бәйгедә җиңүчене гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү) билгеләү турында Министрлык боерыгы чыгарыла һәм бәйгедә җиңүче белән хезмәт контракты төзелә.

Бәйге комиссиясе тарафыннан дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә үткәрелгән бәйгедә җиңүче булмаган кандидатны дәүләт органының кадрлар резервына кертү турында карар кабул ителсә, күрсәтелгән зат ризалыгы белән аны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук группа гражданлык хезмәтенең вазыйфаларын биләү өчен шушы органның кадрлар резервына кертү турында дәүләт органы акты чыгарыла.

3.14. Бәйге нәтиҗәләре турында хәбәрләр, ул тәмамланганнан соң 7 көн эчендә, кандидатларга язма рәвештә, шул ук вакытта бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон документ рәвешендә, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасын кулланып җибәрелә. Бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук вакытта «Интернет» челтәрендә Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмати системасының рәсми сайтларында урнаштырыла.

3.15. Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче бәйгегә катнашуга кертелмәгән һәм бәйгедә катнашкан кандидатларның документлары аларга бәйге тәмамланганнан соң өч ел эчендә язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Әлеге вакыт чыкканчы документлар дәүләт органы архивында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Бәйгедә катнашу өчен электрон рәвештә тәкъдим ителгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

3.16. Бәйгедә катнашу (бәйге үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урыны алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбенә гамәлгә ашырыла.

3.17. Кандидат бәйге комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

## IV БӘЙГЕНЕ ҮТКӘРҮ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Бәйгене үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган бәйге биремнәре һәм процедуралар кулланыла.

Кандидатлар өчен мәгълүмат алу мөмкинлеген арттыру, шулай ук кандидатларның үз-үзләрен бәяләү һәм һөнәри дәрәҗәләрен күтәрүгә мотивацияләү максатларында, алар үзләренең һөнәри дәрәҗәсен мөстәкыйль бәяләү өчен, бәйге кысаларыннан тыш беренчел квалификация тесты уза алалар, моның турында бәйге турында белдерүдә күрсәтелә.

4.2. Министрлыкта бәйгене оештыру Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» (алга таба – Бердәм мәгълүмати кадрлар системасы) дәүләт мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

4.3. Бәйге үткәрү барышында бәйге комиссиясе кандидатларны алар тәкъдим иткән белемнәре, гражданлык һәм башка дәүләт хезмәтен узу, башка хезмәт эшчәнлеге башкару турындагы документлар, шулай ук бәйге процедуралары нигезендә шәхси әңгәмә, эссе язу, конституция законнарын, дәүләт гражданлык хезмәте һәм коррупциягә каршы тору турындагы законнарны, рус теле һәм компьютер грамоталылыгын, физик культура һәм спортны белүгә тест үткәрү нигезендә бәяли.

Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә бәйге комиссиясе гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кваалификация таләпләренннән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

4.4. Тест узуны оештыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Министрлыктан бердәм

мәгълүмати кадрлар системасына кергән гаризалар буенча гамәлгә ашырыла.

Тест үткәрү өчен гариза кадрлар хезмәтенең Бердәм мәгълүмати системасында бәйге комиссиясе утырышына кадәр ике атнадан да соңга калмыйча формалаштырыла.

Тест Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11 декабреннән УП-1192 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре» Указы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тест уздыру методикасы буенча гамәлгә ашырыла.

4.5. Бәйгедә катнашучылар шәхси әңгәмә үткәрү датасына кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлык бинасында эссе формасында гамәли эш башкаралар. Эссе темалары министрлыкның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга яки кадрлар резервын формалаштыру буенча бәйге үткәрелә торган структур бүлекчәсе тарафыннан билгеләнә һәм бәйгедә катнашучыларга кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча сектор тарафыннан эссе язу датасына кадәр 7 эш көненнән дә соңга калмыйча җиткерелә. Һәр кандидатка эссене имзалау өчен шәхси код бирелә.

Эссенең күләме басма текстның 2 битеннән дә артык булмаска тиеш (Times New Roman шрифты, 14 размер, 1,5 абзац). Эссе тәнкыйти яки аналитик булырга, авторның конкрет проблемага яки сорауга фикерләрен белдерергә тиеш. Проблематика ике-өч тезис белән тәкъдим ителергә тиеш. Һәр тезис ике саллы дәлил белән ныгытыла (бу статистик мәгълүматлар, абруйлы галимнәрнең һәм (яки) экспертларның фикерләре, авторның тормыш тәҗрибәсе, тарихи фактлар һ.б. булырга мөмкин). Тезислар, бер үк фикерне төрле яссылыкларда күрсәтеп, бер-берсен тулыландыра ала, шулай ук автор фикеренә карап, бер-берсенә каршы килергә мөмкин. Эссенең төп характеристикалары: бөтен, мантыйкый булуы, грамоталылык, конкрет индивидуумның нигезле фикерен җиткерү.

Бәйге комиссиясе әгъзалары кодлаштырылган эсселәрне, кандидатларның үзләре булмаганда гына, 10 баллы шкала буенча материалны бирүнең сыйфаты һәм

тирәнлеге, сорауларны ачуның тулылыгы, дәүләт телләрен белү буенча бәяли.

Шәхси әңгәмә үткәрер алдыннан бердәм тест һәм эссе язу нәтиҗәләре буенча кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча сектор бәяләү кәгазен (1 нче кушымта) тутыра, ул шәхси әңгәмә нәтиҗәләрен кертү өчен бәйге комиссиясе әгъзаларына бирелә.

4.6. Бәйге комиссиясенең шәхси әңгәмәсе барышында бәйге биремнәрен үтәү нәтиҗәләре буенча кандидат белән фикер алышу үткәрелә, аның һөнәри дәрәҗәсен билгеләү максатыннан сораулар бирелә.

4.7. Кандидат белән шәхси әңгәмә тәмамлангач, бәйге комиссиясенең һәр әгъзасы шәхси әңгәмә өчен бәяләү кәгазендә баллар куя, кирәк булганда, бәйге комиссиясе әгъзасы кабул иткән карарны нигезли торган кыска гына дәлил белән.

Бәяләү 10 баллы шкала буенча башкарыла.

4.8. Бәйге комиссиясе сәркатибе, бәйгедә катнашкан барлык бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган баллардан чыгып, кандидатлар рейтингын билгели. Рейтинг алдагы этапларда җыелган баллар нәтиҗәләре буенча уртача арифметик нәтиҗә баллы буенча исәпләнә (кушымта 2).

4.9. Иң күп балл җыйган кандидат җиңүче дип санала. Шул ук вакытта, кандидатны җиңүче дип тану өчен, бердәм тест нәтиҗәләрен исәпкә алып, җыелган балларның гомуми суммасы максималь баллның 60 процентыннан да ким булмаска тиеш.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына кертүгә) үткәрелә торган бәйге
турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта

БӘЯЛӘҮ КӘГАЗЕ

| № | Ф.И.А.и | Вакантлы вазыйфа | Бердәм тест нәтиҗәләре | Практик эш | Шәхси әңгәмә | Нәтиҗә баллы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| 3. | | | | | | |

Бәйге комиссиясе әгъзасы ________________________________

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына кертүгә) үткәрелә торган бәйге
турында Нигезләмәгә 2 нче кушымта

| | Бәйге комиссиясе әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Бәяләү нәтиҗәләре | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Кандидатның Ф.И.А.и | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | Тест | Эссе | Әңгәмә | Уртача балл | Тест | Эссе | Әңгәмә | Уртача балл | Тест | Эссе | Әңгәмә | Уртача балл | Тест | Эссе | Әңгәмә | Уртача балл | Тест | Эссе | Әңгәмә | Уртача балл |
| 1 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | **Барлыгы** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Рейтинг | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Бәйге комиссиясе рәисе ________________

Бәйге комиссиясе сәркатибе ________________